**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Советская, д.81, с.Чубар-Абдуллово, 423323
Тел. (8-292)38-7-30, 38-7-37

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл жирлеге башкарма комитеты**

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы, 423323
Тел. (8-292) 38-7-30, 38-7-37

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15 » август 2017 ел. № 7

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул авыл җирлегенең чыгым йөкләмәләре
реестрын алып бару кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 87 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлегенең чыгым йөкләмәләре реестрын алып баруның кушымта итеп бирелә торган кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге башкарма комитетына Чубар-Абдул авыл җирлегенең чыгым йөкләмәләре реестрын төзүне һәм аны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тапшыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык Н.А. Фәтхетдинов